КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 5 май г.Казань № 311

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кайбер башкарма органнары вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264[1] статьясындагы 6 пункты һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97[1] статьясындагы 4[1] пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) бу карарга теркәлгән кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кайбер башкарма органнарының (алга таба – үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектлары) түбәндәге вәкаләтләрен турыдан-туры гамәлгә ашыра дип билгеләргә:

а) физик затларга хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне һәм башка түләүләрне, шулай ук аларга бәйле булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне исәпләү һәм аларны күчерү;

б) бюджет исәбен алып бару (бюджет хисаплылыгын, бюджет исәбе мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла торган башка мәҗбүри хисаплылык төзүне һәм тапшыруны кертеп), мондый хисаплылыкны тиешле дәүләт органнарына кертүне тәэмин итү.

2. Министрлык тарафыннан бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләр (алга таба – үзәкләштерелә торган вәкаләтләр) үтәлешен оештыру максатларында Министрлыкка бу карар үз көченә кергән көннән биш көн эчендә, срокларын, шул исәптән кирәк булганда үзәкләштерелә торган вәкаләтләрне тапшыру этапларын һәм аның күчү нигезләмәләрен күрсәтеп, чаралар планын («юл картасын») эшләргә.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Министрлыкның үзәкләштерелә торган вәкаләтләрне башкаруы һәм аның үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектлары белән үзара хезмәттәшлек итүе «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан һәм башка дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдаланып тәэмин ителә;

Министрлык тарафыннан үзәкләштерелә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны оештыру тәртибе исәпкә алуны үзәкләштергәндә Министрлыкның бердәм исәпкә алу сәясәте документлары белән билгеләнә;

Министрлык һәм үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектлары арасында хуҗалык тормышы фактларын документаль рәсмиләштерүне тәэмин итү, үзәкләштерелә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) тапшыру (алу) буенча, шулай ук үзәкләштерелә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда формалаштырылган (файдаланыла торган) документларны (мәгълүматларны) үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектларына тапшыру буенча үзара хезмәттәшлек итү исәпкә алуны үзәкләштергәндә бердәм исәпкә алу сәясәте кысаларында Министрлык тарафыннан билгеләнгән документлар әйләнеше кагыйдәләре (исәпкә алуны үзәкләштергәндә документлар әйләнеше графигы) нигезендә оештырыла. Әлеге хезмәттәшлек итү эшкәртелә торган шәхси мәгълүматларны, шулай ук дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматны һәм федераль законнар белән файдалану мөмкинлеге чикләнгән, дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләре булмаган башка мәгълүматны саклау турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла;

үзәкләштерелә торган вәкаләтләрне башкарганда Министрлык тиешле үзәкләштерелгән исәпкә алу субъекты исеменнән Федераль салым хезмәте, Федераль дәүләт статистика хезмәте һәм башка дәүләт органнары, шулай ук Россия Федерациясе Социаль иминият фонды, Россия Федерациясе Пенсия фонды белән хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра;

үзәкләштерелә торган вәкаләтләрне үтәү максатларында Министрлык үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектының шәхси мәгълүматларын эшкәртүне һәм аларны Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә саклауны тәэмин итә.

4. Министрлыкка үзәкләштерелә торган вәкаләтләрнең үтәлешен Министрлык һәм үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектлары арасындагы җаваплылыкны чикләү буенча түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып тәэмин итәргә:

а) Министрлыкның үзәкләштерелә торган вәкаләтләрне башкару йөкләнгән вазыйфаи затлары бюджет яки бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы күрсәткечләрендә җибәрелгән хата өчен, әгәр мондый хата үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектлары тарафыннан төзелгән беренчел исәпкә алу документларының хуҗалык тормышында булган фактларга туры килмәве һәм (яки) беренчел исәпкә алу документларын алардагы мәгълүматларны бухгалтерлык исәбе регистрларында теркәүгә тапшырмау яисә үз вакытында тапшырмау аркасында җибәрелгән булса, җавап бирмиләр.

б) үзәкләштерелгән исәпкә алу субъекты җитәкчесе һәм Министрлык арасында бюджет исәбен алып баруга карата түбәндәге фикер каршылыклары барлыкка килгән очракта:

бухгалтерлык исәбе регистрларында теркәү һәм җыеп бару өчен беренчел исәпкә алу документындагы мәгълүматлар Министрлык тарафыннан кертелә торган мәгълүмат өчен үзе генә җавап бирүче үзәкләштерелгән исәпкә алу субъекты җитәкчесенең язма боерыгы нигезендә кабул ителә (кабул ителми);

бюджет исәбе объекты бюджет хисаплылыгында Министрлык тарафыннан хисап датасына карата үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектының финанс хәле турында, хисап чоры өчен аның эшчәнлеге буенча финанс нәтиҗәләре һәм акча хәрәкәте турында кертелгән мәгълүматның дөрес булмавы өчен үзе генә җавап бирүче үзәкләштерелгән исәпкә алу субъекты җитәкчесенең язма боерыгы нигезендә чагылдырыла (чагылдырылмый).

5. Бу карар нигезендә үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектлары җитәкчеләренә кирәкле оештыру-штат чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 5 май, 311 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан физик затларга хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне һәм башка түләүләрне, шулай ук аларга бәйле булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне исәпләү һәм аларны күчерү, бюджет исәбен алып бару (бюджет хисаплылыгын, бюджет исәбе мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла торган башка мәҗбүри хисаплылык төзүне һәм тапшыруны кертеп), мондый хисаплылыкны тиешле дәүләт органнарына кертүне тәэмин итү буенча вәкаләтләр гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары
исемлеге

1. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы.
2. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты.
3. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты.
4. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты.
5. Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе.
6. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе.
7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе.

_______________________________